**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы**

Бирючевка авылы № 146 « **24** » сентябрь 2019 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Бирючевка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 150 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга асфальт җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Мира ур.,Бирючевка авылы; Молодежная ур., Бирючевка авылы;

-авыл халкына бәйрәмнәрне оештыру өчен: “Сабантуй”,”Картлар көне”,”Яна ел” бәйрәмнәре өчен;

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Бирючевка авылы, Мәктәп ур., 2 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис: Нуреева М.Г.